| Республика Татарстан<br>Старо-Имянское сельское<br>поселение Сармановского<br>муниципального района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль<br>районының Иске Имән<br>авыл җирлеге |
|---|---|

**КАРАР**
**15.01.2025 ел**

**КАРАР**
**№124**

Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге Советының 2020 елның 27 февралендәге «Җир салымы турында» 145 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Салым кодексының 31 нче бүлеге, Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2024 елның 12 июлендәге 175-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Иске Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Иске Имән авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге Советының 2020 елның 27 февралендәге «Җир салымы турында» 145 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1.2.1. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2.1. торак фонды һәм торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлештән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата, әлеге абзацта күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән тыш, эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләрен һәм аларның һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган җир кишәрлекләрен";

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән 1 айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

3. Әлеге карарны “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында” (PRAVO TATARSTAN. RU) һәм Татарстан Республикасы “Сарман муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге
Советы рәисе Р.Ә.Исламова

Муниципальное образование Сармановский муниципальный район Республики Татарстан. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы муниципаль берәмлеге. ОГРН 1021601312974. Совет Старо-Имянского сельского поселения. Иске Имән авыл җирлеге Советы. ИНН 1636001989